ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

_________24.12.2025________ № _923_____

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Сәламәтлек саклау өлкәсендә 2025-2026 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 22 гыйнварындагы 70 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Сәламәтлек саклау өлкәсендә 2025-2026 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасын раслау турында» 2025 елның 22 гыйнварындагы 70 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтадагы 3 бүлекнең дүртенче, бишенче абзацларында, 4 бүлекнең дүртенче абзацында «(физик затлар керемнәренә салым түләүне исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Карарга 2 нче кушымтаның 3 пунктындагы 3.3 пунктчасының беренче, икенче абзацларында «(иминият кертемнәрен һәм физик затлар керемнәренә салым түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы сәламәтлек саклау системасы медицина учреждениеләренең медицина хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә бер мәртәбә матди түләү бирү тәртибенә 3 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 2.2 пунктының 2.2.1 пунктчасында «(иминият кертемнәрен һәм физик затлар керемнәренә салым түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин